КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 11 ноябрь г.Казань № б-2462

Татарстан Республикасы Президентының «Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасын саклау турында конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум оештыру һәм уздыру турында» 2022 елның 4 октябрендәге 319 номерлы боерыгының 2 пунктын һәм Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасын саклау турында конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитетының читтән торып үткәрелгән утырышының 2022 елның 8 ноябрендәге беркетмәсен үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасын саклау турында конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны әзерләү һәм үткәрү буенча төп чараларның республика планын (алга таба – План) расларга.

2. «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасын Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасын саклау турында конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны әзерләү һәм үткәрү буенча башкарма оешма дип билгеләргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Планны мәгълүмати яктыртуны тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының
2022 ел, 11 ноябрь, б-2462 нче
боерыгы белән расланды

Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасын саклау турында конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан
Халыкара форумны әзерләү һәм үткәрү буенча төп чараларның республика планы

| Т/с | Чараның исеме | Башкару срогы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Финанс белән тәэмин итү | | | |
| 1.1. | Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасын саклау турында конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны (алга таба – Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум) әзерләү һәм үткәрәү буенча төп чараларны тормышка ашыруны финанс белән тәэмин итү күләмнәрен һәм чыганакларын билгеләү | 2022 елның ноябре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча), Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты |
| 1.2. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны әзерләү һәм үткәрү буенча башкарма оешма эшчәнлеген тәэмин итү | 2022 елның ноябре – декабре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 2. Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум чараларын үткәрү планлаштырыла торган объектларны, шәһәр инфраструктурасы объектларын әзерләү, Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның техник координацияләү * | | | |

*Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум чараларын үткәрү планлаштырыла торган объектлар исемлеге бу Республика планына теркәлгән кушымтада китерелде.

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 2.1. | Чараның оештыру комитеты, чараны оештыруга җәлеп ителгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкилләрен TETRA стандартындагы хезмәт урынында куллану өчен билгеләнгән һөнәри цифрлы радиоэлемтә терминналары белән тәэмин итү | 2022 елның декабре | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 2.2. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум объектларын түбәндәгеләр белән тәэмин итү:<br>өзлексез электр белән тәэмин итү | 2022 елның<br>4 – 9 декабре | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |
| | мәгълүмат-коммуникация һәм телекоммуникация инфраструктурасы | | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы |
| | җиһаз һәм чыгым материаллары | | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 2.3. | Шәһәр инфраструктурасы объектларын әзерләү, шул исәптән шәһәр буенча мәгълүмат һәм реклама баннерларын урнаштыру, Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумда катнашучыларның уңайлы һәм имин яшәвен тәэмин итү | 2022 елның<br>ноябре – декабре | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасының Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасының Спас муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Спорт |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 3. Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның эшлекле өлешен тәэмин итү | | | |
| 3.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның беркетмә атрибутикасы эскизларын эшләү, килештерү һәм раслау | 2022 елның ноябре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 4. Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның клиентлар төркемнәре сервислары белән тәэмин итү | | | |
| 4.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның клиентлар төркемнәре килү һәм китүнең фараз графигын эшләү (пассажирлар агымын анализлау) | 2022 елның ноябре | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| 4.2. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны транспорт белән тәэмин итүнең операцион планын эшләү | 2022 елның ноябре | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча), Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча) |
| 4.3. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның беркетмә маршрутларын эшләү, килештерү һәм раслау | 2022 елның ноябре | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча), Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы ми- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | нистрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 4.4. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның клиентлар төркемнәре тукклануын оештыру концепциясен әзерләү һәм аны Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре комиссиясе Секретаре белән килештерү | 2022 елның ноябре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 4.5. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның клиентлар төркемнәре урнашуын оештыру концепциясен әзерләү һәм аны Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре комиссиясе Секретаре белән килештерү | 2022 елның ноябре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 4.6. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумда катнашучылар һәм аның кунаклары өчен таможня һәм чик буе контролен тәэмин итү | 2022 елның 1 – 9 декабре | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсенә караган Татарстан таможнясы (килешү |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | буенча), Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 5. Хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү | | | |
| 5.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум чаралары иминлеген тәэмин итү буенча чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру, шул исәптән террорчылыктан саклану таләпләрен исәпкә алып, форумны инфраструктура объектлары белән тәэмин итү | 2022 елның ноябре – декабре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча), Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 5.2. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум объектларында тикшереп үткәрү режимын һәм аларны саклауны | 2022 елның ноябре – декабре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Спорт һәм со- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | оештыру максатларында башкаручыларны билгеләү, шартнамәләр төзү | | циаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 6. Мәдәният программасын эшләү һәм тәэмин итү | | | |
| 6.1. | ЮНЕСКО бөтендөнья мәдәни мирасы объектларына, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә мәдәни мирас объектларын саклау эшенә багышланган фотокүргәзмә оештыру һәм үткәрү | 2022 елның декабре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, Татарстан Республикасының Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен торгызу республика фонды (килешү буенча), «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 6.2. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумда катнашучылар һәм аның кунаклары өчен мәдәни һәм экскурсия программаларын формалаштыру | 2022 елның ноябре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 6.3. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны | 2022 елның ноябре | Татарстан Республикасы Мәдә- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | үткәрүгә багышланган тантаналы чараларның сценарие планын эшләү, килештерү һәм раслау, шулай ук, Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре комиссиясе Секретариаты белән килештереп, Халыкара форумны ябуга багышланган тантаналы кабул итүне эшләү | | ният министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 7. Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре эшләү өчен җәмәгатьчелек белән элемтәләрне тәэмин итү, сервислар оештыру | | | |
| 7.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны әзерләүне һәм үткәрүне мәгълүмати яктырту, Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум программасы чараларын фотога һәм видеога төшерүне оештыру | 2022 елның ноябре – декабре | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 7.2. | Массакүләм мәгълүмат чараларының аккредитацияләнгән вәкилләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен матбугат объектлары, шулай ук трансляцияләрне оештыру турында карар факты буенча телевизион тапшырулар һәм (яки) интернет-тапшырулар объектлары исемлеген билгеләү һәм раслау | 2022 елның ноябре | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 7.3. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум программасы чаралары кысаларында массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен сервислар оештыру | 2022 елның ноябре – декабре | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча), Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 8. Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумда катнашучыларны аккредитацияләү | | | |
| 8.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумда катнашучыларның барлык категорияләре өчен аккредитация | 2022 елның ноябре | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | процедурасы регламентын эшләү | | автоном оешмасы (килешү буенча), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) |
| 9. Медицина белән тәэмин итү | | | |
| 9.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны медицина белән тәэмин итү чаралары планын эшләү һәм раслау | 2022 елның ноябре | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 10. Волонтерлар программасы | | | |
| 10.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны оештыру һәм үткәрү өчен волонтерлар җәлеп итү һәм әзерләү, яшьләр арасында волонтерлык хәрәкәтен популярлаштыру программасын тормышка ашыру | 2022 елның ноябре | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 11. Экипировка белән тәэмин итү | | | |
| 11.1. | Клиент төркемнәрен экипировка белән тәэмин итү | 2022 елның ноябре – декабре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 12. Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны санитария-эпидемиология ягыннан тәэмин итү | | | |
| 12.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форум үткәрелә торган урыннарда, анда катнашучылар һәм аның кунаклары яшәү һәм туклану урыннарында санитария-эпидемиология тикшерүен үткәрү | 2022 елның декабре | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| 12.2. | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның клиентлар төркемнәре туклануын оештыру концепциясен килештерү | 2022 елның ноябре | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 12.3. | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе белән Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның клиентлар төркемнәре тарафыннан сатыла торган ашамлыклар менюсын һәм аларның ассортимент исемлекләрен килештерү | 2022 елның ноябре | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» коммерциягә карамаган автоном оешмасы (килешү буенча) |
| 13. Төп чаралар планын үтәүне координацияләү | | | |
| 13.1. | Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумның төп чаралары планы үтәлешен мониторинглауны тәэмин итү | 2022 елның ноябре – декабре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |

Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасын саклау турында конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан Халыкара форумны әзерләү һәм үткәрү буенча төп чараларның республика планына кушымта

Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасын саклау турында конвенциянең
50 еллыгына уңаеннан Халыкара форум чараларын үткәрү планлаштырыла торган
объектлар исемлеге

| Т/с | Чараның исеме | Үткәрү урыны |
|---|---|---|
| 1. | Пленар утырыш | С.Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залы |
| 2. | Тантаналы сәламләү | «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексы |
| 3. | Бөтендөнья мирас объектлары белән идарә итүчеләр конференциясе | «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексы |
| 4. | Сәнәгать мирасы буенча конференция | «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексы |
| 5. | «Бөек ефәк юлы» конференциясе | «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексы |
| 6. | «Пальмираны травма алганнан соң торгызу мәсьәләләре» халыкара конференциясе | «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексы |
| 7. | Дини мирас буенча конференция | Казан Кремленең Дәүләт учреждениеләре һәм административ биналар комплексы |
| 8. | Бөтендөнья мирасы өлкәсендә яшь белгечләр конференциясе | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең төп бинасы |
| 9. | ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының яшьләр моделе | Казан шәһәренең «Адымнар – белемнәргә һәм татулыкка юл» полилингваль комплексы» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе |
| 10. | Россия Федерациясе ЮНЕСКО эшләре буенча илкүләм комиссияләренең җаваплы секретарьлары очрашу | Казан Ратушасы |
| 11. | Тәмамлау утырышы | «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексы |